| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2022 г.Зеленодольск № 226

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2017 елның 12 октябрендәге 240 номерлы карары белән (2018 елның 23 апрелендәге 290 номерлы, 2018 елның 9 июлендәге 312 номерлы, 2019 елның 4 мартындагы 368 номерлы, 2019 елның 8 августындагы 420 номерлы һәм 2020 елның 11 августындагы 511 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган, Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары белән расланган, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль -исәп органнары рәисләренең, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 13 декабрендәге 1222 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2017 елның 12 октябрендәге 240 номерлы карары белән (2018 елның 23 апрелендәге 290 номерлы, 2018 елның 9 июлендәге 312 номерлы, 2019 елның 4 мартындагы 368 номерлы, 2019 елның 8 августындагы 420 номерлы һәм 2020 елның 11 августындагы 511 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 23 статьяның 23.2 пунктында:

1.1.1 8 нче һәм 9 нчы пунктчаларын яңа редакциядә бәян итәргә:

«8) Татарстан Республикасының мактаулы исеме, профильле гыйльми дәрәҗә өчен хезмәт окладына ай саен өстәмә түләү;

9) төп хезмәт бурычларына юрист яки башкаручы буларак хокукый актларга һәм хокукый актлар проектларына хокукый экспертиза уздыру,

хокукый актлар проектларын әзерләү һәм аларны редакцияләү, аларга виза салу кирә торган югары юридик белемгә ия булган муниципаль хезмәткәрләргә ай саен бирелә торган түләү (юридик эш өчен өстәмә түләүләр);»

1.1.2. түбәндәге эчтәлекле 10 нчы пункт өстәргә:

«10) Нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен ай саен түләнә торган компенсация түләве.»;

1.2. 23 статьяның 23.7 пунктында «(катлаулылык, киеренкелек, хезмәттә югары казанышлар, махсус эш режимы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 23 статьяның 23.9. пунктына «, җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын гамәлгә кертүгә бәйле рәвештә җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртеп оештырганда муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәтнең элек биләгән вазыйфасыннан түбәнрәк вазыйфа окладлы вазыйфасына билгелән очрактан башка, бу вакытта акчалата бүләкләү күләмен исәпләү муниципаль хезмәткәрнең акчалата күләмен тәэмин итүне исәпкә алып башкарыла.»; сүзләрен өстәргә;

1.4. 23 статьяның 23.14 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«23.14. Муниципаль хезмәткәрләргә вазыйфаи окладка түбәндәге айлык өстәмә түләүләр:

фәннәр кандидатының профильле гыйльми дәрәҗәсе өчен - вазыйфаи окладның 1,5 проценты күләмендә;

фәннәр докторының профильле гыйльми дәрәҗәсе өчен - вазыйфаи окладның 2 проценты күләмендә;

Татарстан Республикасының мактаулы исеме өчен - вазыйфаи окладның 1,5 проценты күләмендә.»;

1.5. 23 статьяның 23.15 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«23.15. Төп хезмәт бурычларына юрист яки башкаручы буларак хокукый актларга һәм хокукый актлар проектларына хокукый экспертиза уздыру, хокукый актлар проектларын әзерләү һәм аларны редакцияләү, аларга виза салу кирә торган югары юридик белемгә ия булган муниципаль хезмәткәрләргә ай саен бирелә торган түләү (юридик эш өчен өстәмә түләүләр) түбәндәге күләмнәрдә :

| Муниципаль хезмәт вазыйфалары | Юридик эш өчен өстәмә түләүләр күләме, вазыйфаи окладка процентлар |
|---|---|
| Муниципаль хезмәтнең югары вазифалары | 8 |
| Муниципаль берәмлекнең төп вазыйфалары | 6 |
| Муниципаль вазыйфаларны әйдәп баручы вазыйфалары | 4 |
| Муниципаль берәмлекнең өлкән вазыйфалары | 2»; |

1.6. 23 статьяга түбәндәге эчтәлекле 23.17 пункт өстәргә:

«23.17. Нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында вазыйфаи окладның 2 проценты күләмендә эшләгән өчен айлык компенсация түләве.»;

1.7. 23 статьяның 23.18 пунктында:

1.7.1. алтынчы абзацта «, җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын гамәлгә кертүгә бәйле рәвештә җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртеп оештырганда муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәтнең элек биләгән вазыйфасыннан түбәнрәк вазыйфа окладлы вазыйфасына билгелән очрактан башка, бу вакытта акчалата бүләкләү күләмен исәпләү муниципаль хезмәткәрнең акчалата күләмен тәэмин итүне исәпкә алып башкарыла.»;

1.7.2. унынчы абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

« Татарстан Республикасының мактаулы исеме, профильле гыйльми дәрәҗә өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү, - әлеге статьяның 23.14 пункты нигезендә;»;

1.8. 23 статьяның 23.19 пунктында:

1.8.1 пунктчада «(катлаулылык, киеренкелек, хезмәттә югары казанышлар, махсус эш режимы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.8.2. түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча өстәргә:

«7) нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен ай саен түләнә торган компенсация түләве, юридик эш өчен өстәмә түләү һәм профильле гыйльми дәрәҗә, Татарстан Республикасының мактаулы исеме өчен вазыйфа окладка ай саен түләнә торган өстәмә түләү - вазыйфаи окладларның 2,5 проценты күләмдә.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Совет рәисе** **М. П. Афанасьев**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ИНН 1648017831 КПП 164801001
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ